Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советының егерме сигезенче утырышы

Надеждино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

15 декабрь, 2023 ел № 78

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2022 елның 29 апрелендәге 39 номерлы карары (Советның 2023 елның 31 мартындагы 60 номерлы, 2023 елның 30 октябрендәге 74 номерлы карарлары белән расланган үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән туктатырга:

- «Чит ил валютасында муниципаль гарантияләр программасы» 18.1 статьясындагы 3 пунктын;

«Россия Федерациясе валютасында муниципаль гарантияләр программасы» 18.2 маддәсенең 3 пунктын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З.Галәветдинов